ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 390-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.И. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 390-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2002-VI ДС

390-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
М.И. Галиев
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар чыгару – сәнәгатьтә һәм башкача хуҗалыкта файдалану максатларында җир куеныннан табигый хәлдәге яисә беренчел эшкәртелгәннән соң (чистартылган, баетылган) файдалы казылмалар чыгару;»;

б) утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ятма – җир асты байлыкларының разведка үткәрү нәтиҗәсендә запасы исәпләнгән һәм (яисә) бәяләнгән табигый файдалы казылма (файдалы казылмалар) тупланмасы булган өлеше;»;

в) утыз икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«минераль чимал – җир асты байлыкларының (тау токымы, руда чималы һәм башкалар) файдалы казылмасы (файдалы казылмалары) булган һәм беренчел эшкәртелгән (чистартылган, баетылган) өлеше;»;

г) илле алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар – җир куенындагы неорганик яисә органик барлыкка килгән каты, сыек яисә газсыман, химик составы һәм физик үзлекләре табигый хәлдә яисә беренчел эшкәртелгәннән соң (чистартылган, баетылган) сәнәгатьтә һәм башкача хуҗалыкта файдаланырга мөмкинлек бирә торган табигый минераль катлам;

д) алтмышынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирне бозу – ашламаларны, үсемлекләр өчен үсеш стимуляторларын, агулы химикатларны һәм башка куркыныч химик яисә биологик матдәләрне саклаганда, кулланганда һәм транспортировкалаганда алар белән эш итү кагыйдәләрен кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерерлек

итеп бозу аркасында хуҗалык яисә башка эшчәнлек продуктлары белән җирне агулау, пычрату һәм башкача бозу;»;

2) 161 статьяның 1 өлешендә «барлыкка килгән, » сүзләреннән соң «эшкәртелгән,» сүзен өстәргә, «калдыкларның» сүзен «;җитештерү һәм куллану калдыкларының» сүзләренә алмаштырырга;

3) 166 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«166 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалауга таләпләр**

1. Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалау экология таләпләрен, санитария-эпидемиология таләпләрен һәм автомобиль, тимер юл, һава, эчке диңгез һәм диңгез транспорты турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

2. Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалауны оештыру законнар нигезендә түбәндәге шартларны үтәп башкарылырга тиеш:

I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалаганда җитештерү һәм куллану калдыкларының паспорты булу;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалау һәм тапшыру өчен документация булу, анда транспортировкалана торган җитештерү һәм куллану калдыкларының саны, аларны транспортировкалауның максаты һәм илтеп җиткерү урыны күрсәтелгән булырга тиеш;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспорт чараларында транспортировкалауга иминлек таләпләрен үтәү;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалаганда кулланыла торган транспорт чараларында, контейнерларда, цистерналарда хәвефлелек классын күрсәтә торган махсус тамгалар булу.

3. Калдыкларның тиешле хәвефлелек классын белдерә торган махсус аерымлык билгеләренең үрнәкләре, шулай ук мондый билгеләрне калдыклар транспортировкалана торган транспорт чараларына, контейнерларга, цистерналарга төшерү тәртибе федераль башкарма хакимиятнең транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен башкаручы органы тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2, 161, 166 статьяларының аерым нигезләмәләрен «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 14 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 268-ФЗ номерлы Федераль закон), «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 356-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 356-ФЗ номерлы Федераль закон) нормаларына, Россия дәүләт стандартының 2020 елның 1 октябрендәге 732-ст боерыгы белән расланган «Россия Федерациясенең милли стандарты. Әйләнә-тирә мохитне саклау. Җир асты байлыклары. Терминнар һәм билгеләмәләр” ГОСТ Р 59071-2020 (алга таба – ГОСТ Р 59071-2020), Россия дәүләт стандартының 2020 елның 30 сентябрендәге 707-ст боерыгы белән расланган «Россия Федерациясенең милли стандарты. Әйләнә-тирә мохитне саклау. Җирләр. Терминнар һәм билгеләмәләр” ГОСТ Р 59055-2020 (алга таба – ГОСТ Р 59055-2020) туры китерү максатларында эшләнде.

Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясындагы 1 өлешенең хәзерге вакытта гамәлдә булган редакциясендә «файдалы казылмалар чыгару», «ятма», «минераль чимал», файдалы казылма», «җирләрне бозу» төшенчәләре китерелгән.

ГОСТ Р 59071-2020 18, 20, 29, 47 пунктларында «ятма», «минераль чимал», «файдалы казылма», «файдалы казылмалар чыгару» төшенчәләре бәян ителгән.

ГОСТ Р 59055-2020 13 пунктында «җирләрне бозу» төшенчәсе аңлатылган.

Шул ук вакытта, ГОСТ Р 59071-2020, ГОСТ Р 59055-2020 бирелгән төшенчәләр Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясындагы 1 өлешендәге «файдалы казылмалар чыгару», «ятма», «минераль чимал», файдалы казылма», «җирләрне бозу» төшенчәләренә туры килми.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясындагы 1 өлешендәге «файдалы казылмалар чыгару», «ятма», «минераль чимал», файдалы казылма», «җирләрне бозу» төшенчәләрен ГОСТ Р 59071-2020, ГОСТ Р 59055-2020 туры китерү максатында унөченче, утыз беренче, утыз икенче, илле алтынчы, алтмышынчы абзацларына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә. Алар яңа редакциядә бәян ителә.

2023 елның 1 мартыннан үз көченә кергән «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 5 пункты (алга таба - 268-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 1 пунктына үзгәрешләр кертелә, ул калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлек алып

баручы индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга утильләштерелгән, зарарсызландырылган, башка затларга бирелгән яисә башка затлардан алынган калдыкларны исәпкә алуны гына түгел, эшкәртелгән калдыкларны да исәпкә алуны алып бару процедурасын кертә.

Шулай итеп, закон проекты белән 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Экология кодексының 161 статьясындагы 1 өлешенә өстәмә өлешендә үзгәреш кертү максатларында тәкъдим ителә.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 02 июлендәге 356-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 10 пункты (алга таба - 356-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына (алга таба - 89-ФЗ номерлы Федераль закон) калдыкларны транспортировкалауга таләпләргә үзгәрешләр кертелгән, һәм ул яңа редакциядә бәян ителгән.

89-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә калдыкларны транспортировкалау түбәндәге шартларны үтәп башкарылырга тиеш:

I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалаганда җитештерү һәм куллану калдыкларының паспорты булу;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалау һәм тапшыру өчен документация булу, анда транспортировкалана торган җитештерү һәм куллану калдыкларының саны, аларны транспортировкалауның максаты һәм илтеп җиткерү урыны күрсәтелгән булырга тиеш;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспорт чараларында транспортировкалауга иминлек таләпләрен үтәү;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалаганда кулланыла торган транспорт чараларында, контейнерларда, цистерналарда хәвефлелек классын күрсәтә торган махсус тамгалар булу.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, закон проектында Татарстан Республикасы Экология кодексының 166 статьясына да үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын камилләштерергә, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерергә һәм системалы, бердәй хокукый җайга салуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.